ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 г. Заинск № 629

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла торган архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2012 елның 4 июлендәге 1273 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла торган архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2012 елның 4 июлендәге 1273 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Р.Ф. Шатунова
7-07-15